## КЕРЕШ

### Татар теленең антонимнары

Кешеләр, яшәеш барлыкка килгәч тә, предметларны, күренешләрне, билгеләрне, әйбер атамаларын капма-каршы куеп чагыштырып карарга омтылганнар, шул нигездә аларның конкрет мәгънәләрен аера һәм алар турында төшенчәләр формалаштыра алганнар. Аларның бу тәҗрибәсе тирә-юньне танып белү процессында 'яхшы' һәм 'яман', 'уңай' һәм 'кире' кебек төшенчәләрне аерырга булышлык итә. Чынлап та, кискен рәвештә капма-каршы куелган күренеш, предмет һәм төшенчәләр, контраст тормаганнары белән чагыштырганда, һичшиксез, аерма-ачык һәм калку рәвештә кабул ителәләр. Нәтиҗәдә, әкренләп халыкның аңы үсә бара, шуңа бәйле фикерләү дәрәҗәсе дә арта барган. Димәк, телдә антонимнарның үсә баруы кешенең чынбарлыктагы капма-каршы күренешләрне танып белүенә бәйле, һәм бу контрастлык сыйфаты безнең ерак ата-бабаларыбызга да хас һәм мәгълүм күренеш булган.

Антонимнар дип, гадәттә, капма-каршы мәгънәле сүзләргә *(ак – кара, дөрес – ялган, начар – яхшы, бәхет – бәхетсезлек, хак – нахак, үткер(н) – үтмәс, дус – дошман, кайгы – шатлык, монда – тегендә, ерак – якын, бару – кайту, килү – киту, мену – төшу, бар – юк)* әйтәләр.

Семантик үзенчәлекләреннән чыгып караганда, татар телендәге антонимнарны берничә төркемгә бүлеп карарга була:

1. Капма-каршы предметларны, күренешләрне белдерүче антонимнар: *дус – дошман, шатлык – кайгы, мәхәббәт – нәфрәт, тынлык – шау-шу* һ. б.

2. Предметлар һәм күренешләрнең капма-каршы билгеләрен һәм сыйфатларын белдерүче антонимнар: *эре – вак, чын – ялган, якты – караңгы* һ.б.

3. Капма-каршы вакыт төшенчәсен белдерүче антонимнар: *кичә – бүген, көн – төн, былтыр – быел* һ. б.

4. Капма-каршы урын-ара мөнәсәбәтен белдерүче антонимнар: *якын – ерак, уңда – сулда, аста – өстә, югары – түбән* һ. б.

5. Капма-каршы хис-кичереш һәм кеше халәтен белдерүче антонимнар: *сәламәт – авыру, батыр – куркак, җитди – җилбәзәк* һ. б.

6. Капма-каршы хәрәкәтне белдерүче антонимнар: *чыгу – керү, күтәрү – төшерү, ачу – ябу, бару – кайту* һ. б.

Кайбер тикшеренүчеләр *кичә – бүген, бүген – иртәгә, быел – былтыр* кебек рәвешләрне антоним парлар түгел дип билгелиләр [1; Б.16-17], [5; Б.29]. Алар тарафыннан антоним дип *кичә – иртәгә, былтыр – яренгә (киләсе ел)* кебек вакыт рәвешләре генә исәпләнә. Әгәр дә логик үзәк итеп 'хәзерге' яки 'бүгенге' вакыт төшенчәсен алсак, бу карашны дөрес дип санарга була.

Әмма безнең уебызча, *кичә – бүген, быел – былтыр* сүзләре арасында да антонимик мөнәсәбәт-бәйләнеш бар. Моны болай исбат итәргә була: әлеге вакыт төшенчәсен белдергән сүзләрнең урталык ноктасын (логик үзәген) табарга кирәк. Әгәр дә без 'төн' төшенчәсен логик үзәк итеп алсак, аның ике ягында урнашкан 'кичә' һәм 'бүген' төшенчәләре үткән һәм киләчәк вакытны белдерәләр:




Шундый ук капма-каршылык мөнәсәбәте *бүген* һәм *иртәгә* сүзләре арасында да барлыкка килә. Шуңа да бу сүзләр тел антонимнары буларак безнең аңыбызда беркетелгәннәр.

Антонимнарның лексик-семантик табигатенә төшенү өчен, иң элек, *капма-каршы* дигән сүзнең мәгънәсен ачыкларга кирәк. Диалектик логикада янәшә куйгысыз төшенчәләрне (несовместимые понятия) каршылыклы (противоречащие) һәм капма-каршы (противоположные) төшенчәләргә бүлеп йөртәләр.

Каршылыклы төшенчәләр берсен-берсе юкка чыгара. Мәсәлән, *А – А түгел, Б – Б түгел.* Боларның арасында аралык үзәге булмый. Телдәге *йорт – йорт түгел, якын – якын түгел, маллы – малсыз (маллы түгел, малы юк), дәфтәрле – дәфтәрсез (дәфтәрле түгел, дәфтәре юк), бар – барма, укы – укыма* кебек сүз һәм сүз формалары белән белдерелгән төшенчәләр шушы каршылыклы төшенчәләргә туры киләләр. Алар белдергән мәгънәләр бер-берсен бөтенләй юкка чыгара. Боларның арасында аралык төшенчәләрен белдергән сүзләр юк [2; Б.5]. Каршылыклы (контрадиктор) төшенчәләрнең белдерелүе тел белемендә барлык-юклык категориясен барлыкка китерә.

Капма-каршылыклы төшенчәләр билгеле бер логик рәтнең иң читтәге ике өлеше булып тора. Алар арасында өченче бер аралык өлеш, икенче төрле әйткәндә, логик урталык та булырга тиеш. Капма-каршылыклы төшенчәләр бер-берсен инкарь итү белән бергә предметка, күренешкә, билгегә яңа бәя дә бирә. Логикада алар *А – А түгел – Б, Б – Б түгел – С* дип күрсәтелә. Телдә мондый капма-каршылыклы төшенчәләр 'яңа' – 'яңа түгел' – 'иске' төшенчәләр рәтендәге иң читтәге ике төшенчәне белдергән *яңа* һәм *иске* сүзләре белән генә белдерелә алалар. Чынлап та, мондагы *иске* дигән сүз предметка *яңа* дигән сүз аркылы бирелгән бәяне инкарь итә һәм шул ук вакытта аңа яңа бәя дә бирә (*иске*). Татар телендәге *уртача* дигән сүз аралык төшенчә була ала: *тиз – акрын* (аралык төшенчә – 'уртача'). *Сул – уң* (аралык төшенчә – 'урта') дигән сүзләр турында да шундый ук фикерне әйтергә мөмкин. Тел белемендә мондый сүзләр генә антонимнар дип танылырга һәм аталырга тиеш.

Антонимик капма-каршылык тик бер логик рәттә ята, ягъни тиңдәш төшенчәләр капма-каршылыгына нигезләнә. Ә диалектик капма-каршылыкның бер ягы аның икенче ягыннан башка булмый. Шуңа ярашлы, капма-каршы төшенчәләр дә бер-берсе белән бәйләнештә була һәм берсеннән-берсе аерым яши алмый. Әгәр кеше аңында 'иртә' дигән төшенчә булмаса, 'кич' дигән төшенчә дә булмас иде. 'Киң' дигән төшенчәнең кешеләр аңында яшәве 'тар' дигән төшенчәгә турыдан-туры бәйләнгән. Тормышта *яхшы* булмаса, *яман* да булмас иде. Профессор М.Х. Әхтәмовның хаклы билгеләвенчә, "Болар – бер логик рәтнең капма-каршы ике өлеше, бер предметның, күренешнең бер-берсен юкка чыгара торган (взаимоисключающие), шуның белән бергә, берсенең

булуына икенчесе шарт булып торган (взаимопредполагающие), ягъни бер-берсеннән аерым яши алмый торган, капма-каршы яклары. Шунлыктан, аларның берсен әйткәндә үзеннән-үзе икенчесе уйга килә" [2; Б.7].

Диалектик каршылыкның капма-каршы ике ягы мәгънә капма-каршылыгы ягыннан тиң була. Төшенчәләр капма-каршылыгына нигезләнгән антонимнарның да мәгънә капма-каршылыгы ягыннан бер-берсенә тиң булуы шарт. Әгәр бу закончалык бозылса, антонимлык мәгънәсе җуела. *Яшь – өлкән – карт* дигән логик рәттәге *яшь – өлкән* сүзләре тел антонимнары була алмый. Бу парда мәгънә капма-каршылыгы *яшь – карт* парындагы капма-каршылыктан түбән. Бу логик рәттә иң чик ике өлеш *яшь* һәм *карт* дигән сүзләр ярдәмендә белдереләләр. Алар мәгънә капма-каршылыгы (контрар) ягыннан бер-берсенә тип-тигез. Шуңа күрә алар телебездә антоним сүзләр булып кабул ителәләр дә. *Өлкән* сүзе *карт* сүзенең идеографик синонимы буларак *яшь* сүзе белән антонимик мөнәсәбәткә керә ала. Шулай да *яшь – өлкән* парындагы мәгънә капма-каршылыгы, *яшь – карт* пары белән чагыштырганда, кимрәк.

Антоним сүзләр һәрвакыт бер-берсенә капма-каршы рәвештә кулланылып тора. Кайчакта алар парлашып, бер сүзгә әйләнеп тә китә һәм куш (парлы) сүзләр барлыкка китерәләр: *аязлы-болытлы, ары-бире, көне-төне, керделе-чыктылы, уңлы-суллы* һ.б. Аерым алганда, алар бер-берсенә карата капма-каршы мәгънәле сүзләр (антонимнар) булып тора.

Антоним сүзләрнең капма-каршы мәгънәсе бер җөмлә эчендә бергә кулланылганда гына ачык күренә. Мәсәлән:

*Күрәсең, бу болыт берлә гомерлеккә кояш бергә;*

*Шулай бергә бугай:* ***шатлык*** *та* ***хәсрәт*** *канлы яшь берлә.* (Г. Тукай)

*Кичә тәмам булгач та,* ***картлар*** *тарала башлады, ә* ***яшьләр*** *уенга калды* (Г. Әпсәләмов).

Антонимнар бер-берсенә капма-каршы предметларның, күренешләрнең атамасы түгел, ә предметлар, күренешләр үзенчәлегенең атамасы, ягъни предметлар, күренешләр билгесенең яки процессның ике ягы атамасы була. Мәсәлән, *мену – төшү, көн – төн* табигате белән бер-берсенә капма-каршы күренешләр түгел. *Мену – төшү* билгеле бер процессның (хәрәкәтнең) ике чиге: *мену* хәрәкәтнең билгеле ноктадан башланып китүе, ә *төшү* исә кирегә шул ноктага таба юнәлгән хәрәкәтне белдерә һәм бер-берсенә каршы мәгънәдән була, ягъни *мену – төшү* бер генә процессның (хәрәкәтнең) ике поляр чикләре булып тора. Ә *көн – төн* антонимнары исә тәүлек эчендәге вакытның шулай ук ике чиген белдерә. Моннан без антонимик капма-каршылык предметлар, күренешләр арасындагы капма-каршылык түгел дигән нәтиҗәгә киләбез. Әгәр антонимик мәгънә предметлар, күренешләр арасындагы каршылык булса, спектр рәтенең ике полюсы булган *көрән* һәм *кызыл* төсләр бер-берсенә антонимнар дип каралыр иде. Әмма алар антоним була алмый. Киресенчә, спектр рәтендә бер-берсенә якын торган *ак* һәм *кара* төсләрен белдергән сүзләр антоним пар була, чөнки кешенең күзе иң элек яктылыкны, аннан гына төсләрне аера. Төсләр арасында *ак* төс иң яктысы, иң ачыгы. Ә *кара* төс иң караңгы төс булып кабул ителә [2; Б.8-9]. Шулай итеп, *ак – кара* дигән сүзләр, *якты* һәм *караңгы* дигән сүзләр белән ассоциатив рәвештә бәйләнеп, антоним пар (иш) төзи. Антоним парлар бер логик рәттә, бер дәрәҗәдә бер-берсенә капма-каршы яткан ике торле билгенең атамасы санала. Бу – антонимик үзенчәлекләрнең берсе.

Антоним сүзләр күчмә мәгънәдә дә кулланыла. Ә логик төшенчәләр күчмә мәгънәдә кулланылмый, чөнки төшенчә һәрвакыт анык була. Телдә берничә сүз бер генә төшенчәне белдерергә мөмкин. Антонимнарның логик капма-каршылыклы төшенчәләрдән аермасы менә шунда да инде.

Антонимнар полисемантик сүзләр белән тыгыз бәйләнештә тора. Күпмәгънәле (полисемантик) сүзләрнең барлык яки кайбер мәгънәләре (лексик-семантик вариантлары) башка сүзләр белән антонимик бәйләнешкә керә алалар. Мисалга *сүтү* сүзен карыйк. Аның һәр аерым мәгънәсе (лексик-семантик варианты), аерым сүзләргә каршы куелып, берничә антоним пар төзи: *сүтү*$_1$ *– тегү, сүтү*$_2$ *– үрү, сүтү*$_3$ *– ишү, сүтү*$_4$ *– чорнау, сүтү*$_5$ *– төрү, сүтү*$_6$ *– салу, сүтү*$_7$ *– кору*. Телебездә *җиңел* сүзе дә күпмәгънәле. Бер мәгънәсе белән *җиңел*$_1$ *– авыр* антоним пар ясый алса, икенче мәгънәсе белән *җиңел*$_2$ *– кыен* парын барлыкка китерә. Үз чиратында *кыен* сүзе ике мәгънәгә ия булып, ике антонимик пар төзи: *кыен*$_1$ *– ансат* һәм *кыен*$_2$ *– рәхәт*. Шулай итеп, күпмәгънәле сүз, нинди мәгънәдә кулланылуына карап, берничә сүзгә антоним булып килә ала.

Кайбер очракта туры мәгънәсендә антоним булмаган сүзләр күчмә мәгънәләрендә башка сүзләр белән антоним пар төзергә мөмкин. Мәсәлән, *баш* һәм *тамак* сүзләрен алып карыйк. Алар үзләренең туры мәгънәләрендә антоним түгел. Ә "агымсуның башланып киткән җире" һәм "агымсуның башка сулыкларга кушылган яки күлгә, диңгезгә койган урыны, җире" дигән күчмә мәгънәләрендә кулланылып, алар антоним пар төзи: *(елганың) башы – (елганың) тамагы.*

Антонимнар синонимнар белән дә үзенчәлекле бәйләнештә торалар. Телебездә *тар – киң* сүзләре антонимнар. *Тар* сүзенең *кысынкы* дигән мәгънәдәш сүзе (синонимы) бар. Бу сүз антонимик мөнәсәбәткә *киң* сүзе белән керә. Бу сүзләр үзара түбәндәге антоним парлар төзи алалар: *тар – киң, кысынкы – киң.*

Телебездә бер синонимик рәттәге сүзләр икенче бер синонимик рәттәге сүзләргә каршы мәгънәдәш булып килергә дә мөмкин. Алар бер-берсенә каршы куелып, берничә антоним парлар барлыкка китерә алалар. Мәсәлән, *сау, сәламәт* һәм *авыру, сырхау* синонимик рәттәге сүзләрдән *сау – авыру, сау – сырхау, сәламәт – авыру, сәламәт – сырхау* кебек антоним парлар төзелә ала.

Телебездә шулай ук мондый күренешне дә күзәтергә була: бер сүзгә берничә синоним сүз каршы куела. Мәсәлән, *бай* сүзенә үзара синоним булган *ярлы, хәерче, фәкыйрь, гидай* сүзләре каршы куелып, шундый антоним парлар (ишләр) ясала ала: *бай – ярлы, бай – хәерче, бай – фәкыйрь, бай – гидай.*

Лексик мәгънәләреннән чыгып, кайбер омонимнар төрле сүзләр белән капма-каршы бәйләнешкә керә алалар һәм антоним парлар барлыкка китерәләр. Мәсәлән: "баегу, мал-мөлкәтле булу" мәгънәсендәге *баю* сүзе белән "бату, офык артында югалу" мәгънәсендәге *баю* сүзе – омонимнар. Шуларның берсе *ярлылану, бөлү* сүзләре белән, ә икенчесе *калку, чыгу* сүзләре белән антоним парлар төзи ала: *баю – бөлү, баю – ярлылану; баю – калку, баю – чыгу.* "Чыгу, офык артыннан күтәрелү" мәгънәсендәге *калку* сүзе "күтәрелеп торган; чыгынкы, кабарынкы" мәгънәсендәге *калку* сүзе белән омонимнарны барлыкка китерәләр. Үз чиратында "күтәрелеп торган; чыгынкы, кабарынкы" мәгънәсендәге *калку* сүзе *батынкы* сүзе белән антоним пар (иш) барлыкка китерә: *калку – батынкы.*

График рәвештә моны болай күрсәтергә мөмкин:

*баю* I ⟷ *бөлү*

*баю* II ⟷ *калку* I

*калку* II ⟷ *батынкы*

Шулай итеп, антонимия (капма-каршылык күренеше) лексиканың полисемия, синонимия, омонимия күренешләре белән тыгыз бәйләнештә тора.

Барлык төрки телләрендәге кебек, татар телендә дә юклык категориясе *-сыз, -сез, -ма, -мә* аффикслары һәм *түгел, юк* сүзләре ярдәмендә белдерелә. Бу аффикслар ялганган яки *түгел* кисәкчәсе, *юк* дигән модаль сүз белән бергә кулланылган сүзләр:

1) фактны юкка чыгара (*елга – елга түгел, куян – куян түгел*);

2) предметның, күренешнең сыйфатын юкка чыгара (*күлмәкле – күлмәксез, җырлы – җырсыз*);

3) эшкә, хәрәкәткә чик куя, эшне, хәрәкәтне туктата (*сөйлә – сөйләмә, атла – атлама*).

Болар предметның, күренешнең сыйфатын (билгесен) юкка чыгара торган антонимнар төренә (*кыю – кыюсыз, тыйнак – тыйнаксыз, диндар – динсез*) якын тора. Шуңа күрә дә кайбер тикшеренүчеләр аларны антонимнар дип исәпли.

Исем сүз төркемнәрендәге сүзләргә *-лы, -ле* кушымчалары ялганып, предметтагы, күренештәге билгеле бер сыйфатның бар булуын белдергән сыйфатлар ясала: *җырлы, йортлы, зарарлы, кызыклы, серле, ялкынлы* һ.б. Шул ук сүзләргә *-сыз,-сез* кушымчалары ялганып, предметтагы, күренештәге билгеле бер сыйфатның юклыгын (булмавын) белдергән сыйфатлар ясала: *җырсыз, йортсыз, зарарсыз, кызыксыз, серсез, ялкынсыз* һ.б. Чагыштыр: *җырлы – җыры бар, җырсыз – җыры юк, зарарлы – зарары бар, зарарсыз – зарары юк, серле – сере бар, серсез – сере юк* һ.б. Димәк, *-лы, -ле* һәм *-сыз, -сез* кушымчалары берберсенә каршы мәгънәдәш аффикслар булып торалар. Ләкин бу кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләрдәге мәгънә каршылыгы антонимик капма-каршылык кебек түгел. Алар үзара антонимик мәгънә тудыра алмый. Димәк, *-сыз, -сез* кушымчалары предметлардагы, күренешләрдәге *-лы, -ле* кушымчалары аркылы белдерелгән сыйфатларны юкка чыгара, инкарь итә. Күрүебезчә, *-сыз, -сез* кушымчалары сыйфатларда юклык категориясен белдерүче аффикслар булып тора. Ә антоним парларның икенче сыңарлары шул сыңарлар алдындагы сүз аркылы бирелгән мәгънәне юкка чыгарып кына калмый, шуның белән бергә, предметка, күренешкә бирелгән яңа бәя дә була. *Дымлы туфрак* һәм *дымсыз туфрак* сүзтезмәләрендә *дымлы* сүзе туфракта дымның бар икәнлеген белдереп, туфракның су белән бәйле үзлегенә бәя биргән булып исәпләнә. Ә *дымсыз* сүзе әлеге бәяне юкка чыгара, инкарь гына итә, әмма туфракка яңа билге һәм бәя бирми. Мондый бәяне *дымлы* сүзенә капма-каршы мәгънә белдерүче *коры* сүзе генә белдерә ала. Димәк, *дымлы* һәм *коры* сүзләре, семантик яктан антонимик мөнәсәбәткә кереп, антоним пар (иш) төзиләр. *Дымлы – дымсыз* сүзләре сыйфатларда барлык-юклык категориясен белдерүче сүзләр генә була. *Шатлыклы* хәбәр һәм *шатлыксыз* хәбәр сүзтезмәләрендәге *шатлыклы* һәм *шатлыксыз* сүзләре турында да шул ук фикерне әйтергә мөмкин. Бирелә *шатлыклы* сүзенә капма-каршы төшенчәне, кеше халәтенә яңа бәяне *кайгылы* сүзе яки аның синонимнары гына бирә ала: *шатлыклы – кайгылы, шатлыклы – хәсрәтле, шатлыклы – хафалы*. Ә *шатлыклы* һәм *шатлыксыз* сыйфат сүзләре –

бер үк сүзнең барлык-юклык формалары гына. Болар инде логикадагы бер-берсен юкка чыгара торган каршылыклы (контрадиктор) мәгънәле төшенчәләргә туры килә. Ә алардагы мәгънә каршылыгы антонимик капма-каршылыктан түбән, көчсез һәм күпкә кайтыш.

Шулай итеп, *-лы, -ле,* һәм *-сыз, -сез* кушымчалары ярдәмендә ясалган сүзләр бер-берсенә каршы мәгънәле сүзләр булсалар да, антоним парлар (ишләр), ягъни капма-каршы мәгънәле сүзләр төзи алмыйлар. Боларның бер ишеләре (*-лы,-ле* кушымчалары) сыйфатларның барлык төрен, ә икенчеләре (*-сыз,-сез* кушымчалары) юклык төрен генә ясыйлар.

Юклык мәгънәсен белдергән кушымчаларның бер төре *(-ма, -мә, -мый, -ми, -мас, -мәс)* хәрәкәтне, эш-хәлне белдерүче сүзләргә, ягъни фигыльләргә генә ялгана. Мәсәлән: *бие – биемә, бар – барма, укы – укыма, йөз – йөзмә, җырла – җырлама* һ.б. Бу парларның беренче сыңарлары *(бие, бар, укы, йөз, җырла)* хәрәкәтнең барлыгын, башкарылырга өндәлгәнлекне белдерә. Икенче сыңарлары *(биемә, барма, укыма, йөзмә, җырлама)*, киресенчә, эш-хәрәкәтнең булмаганлыгын, туктгалып калганлыгын белдерә, ягъни беренчеләр аркылы бирелгән мәгънәне юкка чыгара. Димәк, алар бер генә фигыльнең барлык һәм юклык формалары булып тора. Ә фигыль антонимнар хәрәкәтнең капма-каршы юнәлешен *(бару - кайту)* яки хәрәкәт иясенең хәлен *(ачу – йому)* белдерә. Югарыда китерелгән мисалларда *(бие – биемә, бар – барма, укы – укыма, йөз – йөзмә, җырла – җырлама)* фигыль антонимнарга хас булган мондый семантик үзенчәлекләр табылмый. Бу парларның икенче сыңарлары инде, хәрәкәтне юкка чыгару белән генә чикләнә, субъектның барлык формасы аркылы бирелгән хәленә яки хәрәкәтнең юнәлешенә капма-каршы яңа хәлне яки юнәлешне белдерми. Шунлыктан, алар антоним сүзләр (парлар) була алмыйлар. Антоним сүзләр бергә кулланылганда үзләренең антонимлык мәгънәләрен югалтмыйлар, киресенчә, капма-каршы мәгънә көчәя, ачыклана гына. Димәк, фигыльләрнең юклык формалары үзләренең барлык формаларына карата антоним парлар (ишләр) төзи алмый.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, татар телендә тамырдаш антонимнар бөтенләй булмый дигән нәтиҗә ясау да дөрес булмас иде. Телебездә төрле тамырдан булган антонимнар *(ак – кара, дус – дошман, бару – кайту, кичә – бүген, их! – тфү!, на! – тырр!)* белән рәттән *бәхет – бәхетсезлек, үткер – үтмәс, оту – отылу, хак – нахак, телчән – телсез, кызганучан – кызганусыз* кебек сүзләр антоним парлар дип карала. Алар алда билгеләнгән *дымлы – дымсыз, шатлыклы – шатлыксыз, бар – барма, җырла – җырлама* тибындагы сүзләрдән нык аерыла. Менә бу парларның *(бәхет – бәхетсезлек, үткер – үтмәс, оту – отылу, хак – нахак, телчән – телсез, кызганучан – кызганусыз)* һәр сыңары үзаллы, аерым сүз булып торса, *дымлы – дымсыз, шатлыклы – шатлыксыз, бар – барма, җырла – җырлама* тибындагы сүзләр исә бер үк сүзнең барлык-юклык формаларын гына төзи. Шулай итеп, капма-каршы мәгънәле парны антоним дип карау өчен, шушы парны төзүче һәр сүз телдә аерым, үзаллы сүз булып танылырга да тиеш.

Тамырдаш антонимнар ясауда югарыда билгеләнгән *-лы,-ле* һәм *-сыз,-сез* кушымчаларыннан башка татар телендә янә *-чан,-чән* һәм *-сыз,-сез; -дар,-дәр* һәм *-сыз,-сез* кебек кушымчалар да катнашалар. Мәсәлән: *телчән – телсез, сүзчән – сүзсез, кызганучан – кызганусыз, диндар – динсез* һ.б.

Энантиосемия – сүздәге мәгънәләрнең поляр каршы куелуы – капма-каршылыкның үзенчәлекле структур төре. Табигате буенча аның кайбер төрләре полисемиягә, ә кайберсе омонимиягә якын торалар. Бу фикер кайбер галимнәргә телнең бу үзенчәлекле күренешен полисемия һәм омонимия чикләрендә тикшерергә мөмкинлек бирә. Энантиосемиянең, ягъни бер үк сүзнең капма-каршы мәгънәдә кулланылуы башка галимнәр тарафыннан да таныла [3].

Татар телендә энантосемиянең ике төрен бүлеп карарга була:

1) бер сүзнең лексик-семантик вариантларының үзара каршы мәгънәдә кулланауы (күпмәгънәлелек);

2) бер мәгънәдәге каршылык (мәгънә диффузиясе) [4; Б.3].

Беренче төр энантиосемия сүзнең мәгънә үсешендә барлыкка килә. Мәсәлән, *дан* – 1. яхшы хәбәр; 2. яман хәбәр мәгънәсендә, *алу* – 1. эшкә алыну (урнашу) һәм 2. эштән алыну (чыгару) мәгънәсендә, *буяу* – 1. матурлау һәм 2. пычрату мәгънәсендә булырга мөмкин. Икенче төр каршылык күренеше (диффузлык) уңай мәгънәдәге сүзнең тискәре мәгънәдә кулланганда һәм кире мәгънәдәге сүзнең уңай мәгънәдә кулланганда барлыкка килә. Мәсәлән, *батыр* сүзе уңай мәгънәдә *кыю*, ә тискәре мәгънәсендә капма-каршы булган антонимик пары *куркак* мәгънәсендә кулланыла. Сүзнең тискәре мәгънәдә кулланылуын контекст, ситуация, басым (эмфатик), тон, мимика, хәрәкәт аша аңлап була. Энантиосемиянең бу төре телебездә киң таралган.

Антонимнар барлык сүз төркемнәрендә диярлек табыла.

Исемнәрдә: *калкулык – түбәнлек, кайгы – шатлык, үлем – яшәү* (тереклек), *дөреслек – ялган* һ.б.

Сыйфатларда: *әче – төче, югары – түбән, зур – кечкенә, кыен – ансат, эре – вак, каты – йомшак, таза – черек, яхшы – яман, очлы – тупак, озын – кыска, итәгатьле – тупас, гыйлемле – надан, матур – ямьсез, биек – тәбәнәк, коры – юеш, чиста – пычрак* һ.б.

Фигыльләрдә: *яту – тору, бару – кайту, бирү – алу, йоклау – уяну, бикләү – чыгару, сугышу – ярашу, баю – бөлү, бату – калку, чыгу – керү, күтәрү – төшерү, мену – төшү, кабызу – сүндерү* һ.б.

Рәвешләрдә: *әле – бая, бүген – иртәгә, кышын – җәен, үткән – киләчәк, көндезен – төнен, иртәле – кичле, тегеләй – болай, аз – күп* һ.б.

Алмашлыкларда: *алай – болай, теге – бу, андый – мондый, тегендә – монда, һәркем – һичкем* һ.б.

Ярдәмлек сүзләрдә: *алдында – артында, бер яктан – икенче яктан, астында – өстендә* һ.б.

Модаль сүзләрдә: *бар – юк, әйе – юк* һ.б.

Ымлыкларда: *их (соклану) – фуу, тфу (чиркану), исәнмесез – сау булыгыз, на! – тыр-р!* һ.б.

Антоним сүзләргә контекст эчендә даими рәвештә кулланылып тору хас. Мәсәлән Г. Тукай иҗатында ("Сайланма әсәрләр"е буенча, 1974-1977) *бай – ярлы* антонимнары 8, *кайгы – хәсрәт* – 9, *ак – кара* – 6, *аз – күп* – 7, *яхшы – яман* – 6 тапкыр (кабатланулардан башка) кулланылган.

Грамматик яктан антоним сүзләр тик бер генә сүз төркеменнән булырга тиешләр. Мәсәлән, *җәй – кыш* антоним парындагы *җәй* сүзе дә, *кыш* сүзе дә исем сүз төркеменә, *яхшы – яман* парында ике сүз дә сыйфат сүз төркеменә карый. Антонимик парлардагы сүзләр төрле сүз төркеменнән була алмыйлар.

Үзләренең лексик составы буенча антоним парлар төп татар сүзләреннән (*аз – күп, бару – кайту, еш – сирәк, куркак – батыр, тиз – акрын, тук – ач, изгелек – явызлык*) һәм башка телләрдән үзләштерелгән сүзләрдән (*бәхет – бәхетсезлек, диндар – динсез, хәят – мәмәт, хак – нахак, агу – дару, гаепләүче – гаепләнүче, симпатия – антипатия, актив – пассив, прогресс – регресс, революционер – реакционер, революция – контрреволюция, минус – плюс*) тора.

Төзелешләре ягыннан антонимнар түбәндәге төрләргә бүленә:

1. Төп (тамыр) антонимнар: *яз – көз, уң – сул, кер – чык, иртә – кич, теге – бу* һ.б.

2. Ясалма антонимнар: *байлык – ярлылык, диндар – динсез, кызганучан – кызганучсыз* һ.б.

3. Антоним парлы сүзләр: *ызгыш-талаш – дуслык-татулык; барыр-бармас – килер-килмәс; туган-үскән – чит-ят (җирләр); тып-тын – шау-шу* һ.б.

4. Берсе тамыр, икенчесе ясалма сүзләрдән торучы яки берсе парлы сүз, ә икенчесе тамыр сүздән торучы антонимнар: *бай – хәерче, матур – ямьсез, кыйммәт – очсыз, тыныч – хәвефле, акыллы – юләр, аяз – болытлы, азап-михнәт – рәхәт* һ.б.

Капма-каршы мәгънәле сүзләрне *тел* (узуаль, гомумтел) һәм *сөйләм* (речь) антонимнарына бүлеп йөртәләр. Тел антонимнары контексттан тыш торганда да антоним булудан туктамый, аларга контекстның булуы шарт түгел. Ә сөйләм антонимнарының андый сәләтлелеге юк. Аларның капма-каршы мәгънә белдерә алулары фәкать җөмлә составында гына була ала. *Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың* дигән мәкальдә дүрт сүз ике антоним пар барлыкка китергәннәр: *сабанда – ындырда, сайрашмасаң – ыңгырашырсың*. Алар фәкать шушы мәкаль составында гына капма-каршы мәгънә мөнәсәбәтләренә керәләр, ә инде бу контексттан тыш *сабан – ындыр, сайрашу – ыңгырашу* сүзләре үзара антоним сүзләр була алмыйлар, алар фәкать контекстуаль антонимнар гына барлыкка китерәләр.

Антонимнарның капма-каршылыкны белдерүдәге семантик табигате аларны телдә мөһим сурәтләү чарасы итеп кулланырга мөмкинлек тудыра. Тел һәм сөйләм (контекстуаль) антонимнарының сурәт-тасвирлау функциясе шактый киң һәм, әйтергә кирәк, бу мөмкинлек антонимнарның нинди типологик төреннән булуына да бәйле.

Әйтик, координацион төшенчәләрне белдерүче антоним сүзләр өчен күбрәк текстны конструктив яктан оештыра алу функциясе хас. Андый сүзләр күренеш, ситуацияләрнең нигезен (каркасын) төзиләр, шулай ук пространстводагы дәвамлыгын, вакыйгаларның вакыт ягыннан эзлеклелеген дә белдерәләр. Вакыт һәм ераклык ниндидер бер урта ноктадан (нульдән яки координатлар башланышыннан) исәпләнелә, ә бу урта нокта итеп тамашачы яки ситуациядә катнашучы һәм сөйләү моменты алына. Мәсәлән, *Әле* ***уңга*** *таба атлый Муса, әле* ***сулга*** *таба атлый, ләкин бер генә якта да юл катысын тоя алмый* (Ш. Маннур. "Муса"); *Шул арада Габдулла өйнең* ***өске*** *каты һәм* ***аскы*** *кат белән танышып чыкты* (Ә. Фәйзи. "Тукай").

Күренешләрне, образларны контраст куеп тасвирлаганда, геройларның характерларын, кичерешләрен контраст кую белән кире чагыштырулар ясаганда да антоним сүзләр еш кулланалар.

Мәсәлән, Авыр булды аннан аерылу,
Ни әйтсәң дә күңел – күңел шул!
*Авыр* булды миңа *аерылу*,
*Рәхәт* булыр кайткач *күрешү*. *(М. Җәлил)*

Кайвакыт антонимнардан ирония, юмор, сатира тудыру өчен кулланалар:

Икенче көн ни күрәм?!
Бер *елыйм* да бер *көләм*.
Урам тулы хатын-кыз,
Бар да ертык юбкадан. *(М. Җәлил)*

**Кулланылган әдәбият**

1. Әхтәмов М.Х. Башкорт теленең антонимнары//Башкортстан укытучысы. – 1972. – №4 (башкорт телендә).

2. Әхтәмов М.Х. башкорт теленең антонимнар сүзлеге. – Уфа:Башкортстан кит. нәшр.. 1987 (башкот телендә).

3. Усубалиев Б.Ш. Антонимы в киргизском языке: автореф. дисс. канд. филол. наук. – Фрунзе, 1982.

4. Ханбикова Ш.С. Антонимичные значения в слове (энантиосемия) // Лексика и стилистика татарского языка. – Казань, 1982.

5. Шукуров Р. Антонимы узбекского языка. – Ташкент: Фан, 1977.

## СҮЗЛЕКНЕ КУЛЛАНУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА

### Сүзлекнең составы

1. Сүзлек, нигездә, төрле тамырдан булган антонимнардан *(ак – кара, бар – юк, җитез – сүлпән, килү – китү, матур – ямьсез, көньяк – төньяк)* тора. Аның составында шулай ук тамырдаш антонимнар *(кызык – кызганыч, оту – оттыру, очып килү – очып китү, сусыл – сусыз, сабырлык – сабырсызлык, сөю – сөелү, хак – нахак, эшчән – эшлексез)* бар.

2. Сүзлектә антонимик (капма-каршы) мәгънәгә ия булган сүзләр төрле сүз төркемнәреннән алынды.

3. Сүзлеккә телебездә актив кулланылышта булган антоним парлар белән рәттән аз санда булса да антоним алынма сүзләр *(пассив – актив, фронт – тыл)* алынды.

### Сүзлекнең төзелеше

1. Сүзлекнең төп һәм күләмле өлешен сүзлек корпусы тәшкил итә.

2. Сүзлек корпусы сүзлек статьяларыннан тора.

3. Сүзлек статьяларының башында торган антоним парлар калын хәрефләр белән билгеләнде һәм җәяләр эчендә нинди сүз төркеменә караган булулары күрсәтелде. Антоним парлар (ишләр) алфавит тәртибендә вертикаль юнәлештә урнаштырыла:

**аз** (рәв.) – **күп** (рәв.)
**азаю** (ф.) – **күбәю** (ф.)
**ахыр** (ис.) – **баш** (ис.)
**зарарлы** (сыйф.) – **файдалы** (сыйф.)
**шатлык** (ис.) – **кайгы** (ис.) һ.б.